КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 27 август

г.Казань

№ 749

Ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны вакытлыча яшәүгә (шул исәптән вакытлыча опекага) алган Россия Федерациясе гражданнары реестрын формалаштыруга һәм раслауга вәкаләтле Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органы турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Инвалидларны, карт гражданнарны, ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны озата баручы яки вакытлыча яшәүгә (вакытлыча опекага) кабул иткән гражданнарга махсус түләүләрне гамәлгә ашыру кагыйдәләрен раслау турында» 2020 ел, 30 май, 797 нче карары нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгын ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар өчен дәүләт бюджет учреждениесеннән ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны вакытлыча яшәүгә (шул исәптән вакытлыча опекага) алган Россия Федерациясе гражданнары реестрын формалаштыруга һәм раслауга вәкаләтле Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органы итеп билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына 2020 елның июнь аенда ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны вакытлыча яшәүгә (шул исәптән вакытлыча опекага) алган Россия Федерациясе гражданнары реестрын формалаштырырга һәм расларга.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин